ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
САРСАК-ОМГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САРСАК-УМГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.11.2022 Сарсак-Умга авылы № 17

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлеге Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында” 31.03.2020 елның 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 174 статьясы, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында» 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 31.03.2020 елның 8 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлеге Башкарма комитетының карарына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Сарсак-Умга авыл
җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Т.С. Николаева

Татарстан Республикасы Әгерже
муниципаль районы Сарсак-Умга
авыл җирлеге Башкарма
комитетының
24.11.2022 елның 17 номерлы
карары белән расланды

**«Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 31.03.2020 елның 8 номерлы Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлеге Башкарма комитетының карарына үзгәрешләр**

1. Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлеге Башкарма комитетының 31.03.2020 № 8 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибендә:

1) 3 пунктта:

«,муниципаль программаларның структур элементларына» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 12 пунктның 3 абзацын киләсе редакциядә бәян итергә:

" ташламалар түләүчеләргә ихтыяҗ ташламалар алу хокукыннан файдаланган түләүчеләр саны һәм ташламаларны куллану хокукына ия булган түләүчеләр саны яки 5 еллык чорда гомуми түләүчеләр саны белән характерлана.";

3) 12 пунктның 2 абзацында:

«,муниципаль программаларның структур элементларына» сүзләрен төшереп калдырырга.